ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 24 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 10, № 11; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакцияне бәян итәргә:

«1. Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланалар, анда, гарызнамәне җибәреп була торган электрон почта адресын күрсәтеп, үзләренең рәсми сайтларын булдыралар, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның $10^6$ статьясында каралган таләпләргә туры килә торган мәгълүмат системаларында һәм (яисә) электрон хисаплау машиналары өчен программаларда рәсми битләрен булдыралар.»;

2) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 79-ТРЗ